СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 42 от 28.01.2021

на № _от ________

# КАРАР

Саба муниципаль районы Советының 2019 елның 9 апрелендәге 295 номерлы карары белән расланган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләмәгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукларыннан, оператив идарә хокукларыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), муниципаль милек исемлегенә кертелгән, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль милкен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 14.1 статьясы нигезендә (2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы үзгәрешләр белән), Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** Саба муниципаль районы Советының "Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләмәгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукларыннан, оператив идарә хокукларыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), муниципаль милек исемлегенә кертелгән, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль милкен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибен раслау турында һәм исемлеккә кертелгән муниципаль милекне

формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибе” 2019 елның 9 апрелендәге 295 номерлы карары белән расланган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга биләмәгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукларыннан, оператив идарә хокукларыннан, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш), муниципаль милек исемлегенә кертелгән, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль милкен, шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) арендага бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 1.6. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.6. Исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендалаучылар булып авыл хуҗалыгы кооперативлары булган яисә эшчәнлекнең социаль әһәмиятле төрләре белән яисә муниципаль программалар (ярдәмче программалар) белән билгеләнгән эшчәнлекнең өстенлекле төрләре (ярдәмче программалары) белән шөгыльләнүче кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ярдәм күрсәтелми торган кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан тыш, “Һөнәри керемгә салым” махсус салым режимын кулланучы һәм индивидуаль эшкуарлар булмаган физик затлар торырга мөмкин.”

**2.** Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов